# ЧИШМӘ БАШЫ



Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» МБМББУ, ноябрь, 2025 ел № 11

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

1. ***«Татарча олимпиада» җиңүчеләре***
2. ***«Алтын көздә кунакта” (бәйрәм чарасы)***
3. ***Бакчабызда «Психологик атна»***
4. ***«Әни белән бергә» районкүләм бәйге***
5. ***Хәрәкәтле уеннар - тормыш мәгънәсе***

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Р.Г.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.,**
**Хөсәенова В.В.**

**Бакчабызда октябрь ахырында мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында татар теленнән олимпиада уздырылды.**

Олимпиадада балалар язучылары, әкиятләр, дәүләт символлары, татар орнаментлары, геометрик фигуралар, һөнәрләр турында биремнәр бар иде.







**Олимпиада нәтиҗәләре буенча Сәләхов Д.Р. һәм Хөсәинов Ә.Р. 12 нче ноябрьдә Арчаның 3 номерлы башлангыч мәктәбе-балалар бакчасында узган йомгаклау тантанасында катнаштылыр.**

**Белемнәре буенча яхшы күрсәткечләргә ирештеләр.**

**Котлыйбыз!!!**

**Балалар бакчасында бәйрәм - ул һәрвакыт тылсымлы**
**төсләр, балаларның шат тавышы.**
**Бакчабызда «Алтын көздә кунакта» исеме астында бәйрәм кичәсе узды.**

Бәйрәмгә балаларның әниләре дә чакырылды. Кунаклар якты һәм матур, төрле төстәге яфраклар белән бизәлгән залга җыелды. Балалар әйлән-бәйлән уйнадылар, көз турында җырлар җырладылар, күңелле уеннар уйнадылар, биеделәр һәм түземсезлек белән « Көз кызының» килүен көттеләр. Көз кызы үзенең кәрзиненнән тылсымлы маскалар алып, балаларны төрле яшелчәләргә әверелдерде. «Карачкы»га табышмаклар чишәргә булыштылар, ярышларда катнаштылар. Әниләрнең «Шалкан» әкиятен сәхнәләштерүе бәйрәмне тагын да җанландырып җибәрде.







## Ноябрь аенда бакчабызда «Психология атналыгы»  булып узды.

Атнаның һәр көнендә аерым темага әңгәмә - дәресләр оештырылды. «Эмоцияләр көнендә», «Минем гаиләм», «Минем яраткан әнием», «Яхшылыклар көнендә», «Тылсымлы таяк» һ.б.

Бу атна балалар өчен эмоцияләргә бай булды, күңелле һәм файдалы узды. Алга таба да «Психология атналыгы» уздыруны планга керттек.









Шушы көннәрдә генә Әниләр көне уңаеннан Арча районында районкүләм дәрәҗәдә «Әни белән бергә» исемле бәйге уздырылды. Быелгы бәйгенең үзенчәлекле ягы шунда - тәрбияләнүче балалар әниләре белән чыгыш ясарга тиеш иде.

Безнең балалар бакчасыннан уртанчылар төркеменә йөрүче Азалинә һәм аның әнисе - Алсу Заһидуллиналар чыгыш ясады. Азалинә үзе белән матур итеп таныштырып, әнисе белән чегән биюен башкарды. Осталыкларын күреп, жюри аларга лаеклы 2 нче урын тапшырды. **Афәрин!**


МУ "Управление образования" исполнительного комитета Арского муниципального района

ГРАМОТА

Награждается

Загидуллина Азалина

МБДОУ «Мендюшский детский сад»

за II место

в районном конкурсе среди воспитанников дошкольных образовательных организаций Арского муниципального района

"Вместе с мамой"

Начальник МУ "управления образования исполнительного комитета Арского муниципального района Муллахметов Н.Н.

ноябрь, 2025 год





Балалар тормышында уеннарның әһәмиятен кем генә белми. Сәламәтлек белән беррәттән балаларда ирекле ярыш рухы, ижади тапкырлык, өлгерлек рухы кабына. Балалар бакчасында иртәдән кичкә кадәр уен элементлары катнашмаган мизгел юктыр да. Уеннар күп һәм төрле-төрле була. Балалар күбрәк музыкаль уеннарга хәрәкәтләнергә яраталар, рәхәтләнеп теләп уйныйлар. Кечкенәләр төркеменә йөрүче балалар белән дә күбрәк уеннарга өстенлек бирергә тырышабыз.





